КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 13 октябрь г.Казань № 826

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт унитар предприятиеләре булмаган юридик затлар (аларның аерылып чыккан җәмгыятьләре) милкендәге капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыруга һәм (яки) алар тарафыннан күчемсез мөлкәт объектлары сатып алуга бәйле булмаган максатлар өчен әлеге юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджет инвестицияләре бирү турында карарлар кабул итү кагыйдәләрен раслау хакында» 2022 ел, 17 май, 454 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт унитар предприятиеләре булмаган юридик затлар (аларның аерылып чыккан җәмгыятьләре) милкендәге капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыруга һәм (яки) алар тарафыннан күчемсез мөлкәт объектлары сатып алуга бәйле булмаган максатлар өчен әлеге юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджет инвестицияләре бирү турында карарлар кабул итү кагыйдәләрен раслау хакында» 2022 ел, 17 май, 454 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 31 октябрь, 1375 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исеменә «, дәүләт теркәвенә алынырга тиешле эчке йөзү судноларыннан тыш» сүзләрен өстәргә;

1 пунктка «, дәүләт теркәвенә алынырга тиешле эчке йөзү судноларыннан тыш» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт унитар предприятиеләре булмаган юридик затлар (аларның аерылып чыккан җәмгыятьләре) милкендәге капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыруга һәм (яки) алар тарафыннан күчемсез мөлкәт объектлары сатып алуга бәйле булмаган максатлар өчен әлеге юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджет инвестицияләре бирү турында карарлар кабул итү кагыйдәләрендә:

исеменә «, дәүләт теркәвенә алынырга тиешле эчке йөзү судноларыннан тыш» сүзләрен өстәргә;

1.1 пунктка «күчемсез милек объектлары» сүзләреннән соң «, дәүләт теркәвенә алынырга тиешле эчке йөзү судноларыннан тыш» сүзләрен өстәргә;

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин